ГЛАВА КРАСНОГОРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Мира, д.11А, п.с-за. “Мамадышский”,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422165

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КЫЗЫЛ ТАУ АВЫЛЫ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Мира ур., 11А нче йорт, “Мамадыш” совхозы
поселогы, Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422165

тел.(факс): (85563)3-91-14; e-mail: KrGor.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление — Карар

“19” октября 2020 г. — № 9

Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Максим Пүчинкәсе авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча узган гражданнар җыенында катнашучы затларны теркәү турында

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Кызыл Тау авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында" гы 2019 елның 14 октябрендәге 1-47 номерлы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Советы карары белән расланган Нигезләмәнең 3.1 пункты нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. Авыл җирлеге Башкарма комитетының хәрби исәпкә алу буенча инспекторын Гараева Алсу Рахимовнаны Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Максим Пүчинкәсе авылында 2020 елның 11 ноябрендә узачак гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенында катнашучы сайлау хокукына ия булган затларны теркәү өчен җаваплы итеп билгеләргә.
2. Гражданнар җыенында катнашучы затларны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә теркәүне тәэмин итәргә.

3 Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.
4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Кызыл Тау авыл җирлеге башлыгы: /В.А.Гыйззәтуллина /